РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2021 елның 9 феврале** **Чистай шәһәре** **№6/3**

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районының «Чистай шәһәре»
муниципаль берәмлегенең җирдән
файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында мәгълүмат тыңлап фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча 2020 елның 28 декабрендә үткәрелгән гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында комиссия бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Чистай шәһәр Советының 2012 елның 19 декабрендәге 18/7 номерлы карары (Чистай шәһәр Советының соңгы карарлары редакциясендә 30.06.2016 ел № 7/1, 25.08.2016 ел № 8/4, 27.04.2017 ел № 14/5, 28.09.2017 ел 18/4, 02.11.2017 ел №19/2, 14.12.2019 ел №20/13, 21.03.2018 ел №23/5, 29.08.2018 ел №27/1, 24.10.2018 ел № 28/5, 25.12.2018 ел №30/12, 28.02.2019 ел №32/1, 30.04.2019 ел №34/6, 11.06.2019 ел №35/4, 04.09.2019 ел №37/3, 27.11.2019 ел № 41/4, 11.02.2020 ел № 45/5, 13.05.2020 ел № 46/8, 02.09.2020 ел № 50/8, 28.10.2020 ел № 3/4, 15.12.2020 ел № 4/9) белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре Чистай шәһәре территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасының 1 нче кушымтасына Ж-1 «Шәхси торак йортлар төзү зонасы» торак төзелешенең территориаль зонасы чиген үзгәртү һәм Чистай шәһәре, Фрунзе ур., 117 нче йорт чикләрендәге территориясен, шул исәптән 16:54:160102:60 кадастр номерлы, 3064,7 кв.м. мәйданлы җир кишәрлеген Ж-2 «Урта катлы торак йортлар төзү зонасы» зонасына кертү өлешендә үзгәрешләр кертергә (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары М.И. Ксенофонтовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов

Чистай шәһәр Советының
2021 елның 9 февралендәге
6/3 номерлы карарына
1 нче кушымта

Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелә торган үзгәрешләр:

